КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1049

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче; 2016 ел, 23 июнь, 433 нче; 2016 ел, 14 ноябрь, 840 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территория-ләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш терри-торияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү хакында» 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; «Түбән Кама» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1609 нчы; «Чистай» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1610 нчы; «Зеленодольск» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1611 нче һәм «Менделеевск» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 2019 ел, 12 февраль, 123 нче карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктның өченче абзацына «төзү» сүзеннән соң «, аңа үзгәреш кертү,

аны өзү» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

1 нче пунктка «төзү» сүзеннән соң «, аңа үзгәреш кертү һәм аны» сүзләрен өстәргә;

2 нче пунктта:

«төзүгә» сүзеннән соң «, аңа үзгәреш кертүгә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Килешүгә үзгәрешләр кертү өчен алга киткән үсеш территориясе резиденты статусына ия булган юридик зат Башкарма комитетка төзүгә (үзгәреш кертүгә) гариза бирә.»;

5 нче пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) инвестиция проектын тормышка ашыруны финанслау мөмкинлеген раслый торган, шул исәптән үз акчасы бизнес-план буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 проценты дәрәҗәсендә, әмма соратыла торган җир кишәрлегенең агымдагы кадастр кыйммәтеннән артмаган дәрәҗәдә булуын раслый торган документлар.

Гариза бирүченең үз акчасы күләме Россия Федерациясе Финанс министрлыгының үткән ел өчен «Оешмаларның бухгалтерлык хисаплылыгы формалары турында» 2010 ел, 2 июль, 66 нчы «н» боерыгы белән расланган 0710001 нче форма буенча бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының «Капитал и резервлар» дигән III бүлеге йомгаклары буенча раслана.

Агымдагы ел чоры өчен гариза бирүче бәйсез аудит нәтиҗәләре белән расланган югарыда күрсәтелгән форма буенча арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырырга хокуклы;»;

17 нче пунктта «президиумының» һәм «президиумы» сүзләрен төшереп калдырырга;

23 нче пунктта «президиумының» сүзен төшереп калдырырга;

27 нче пунктта «президиумы» сүзен төшереп калдырырга;

33 нче пунктта «президиумы» һәм «президиумы тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $35^1$ – $35^3$ нче пунктлар өстәргә:

«$35^1$. Килешүгә түбәндәгеләр күздә тотылган үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

а) алга киткән үсеш территориясе резидентының инвестицион проекты тормышка ашырыла торган икътисадый эшчәнлек төрләренә үзгәреш кертү;

б) алга киткән үсеш территориясе резидентының инвестицион проекты тормышка ашырыла торган җир кишәрлегенә үзгәреш кертү;

в) алга киткән үсеш территориясе резидентының капиталь кертемнәр күләме һәм оештырыла торган эш урыннары саны буенча йөкләмәләренә үзгәреш кертү;

г) алга киткән үсеш территориясе резидентына бирелә торган преференцияләргә үзгәреш кертү;

д) Килешүнең гамәлдә булу вакытын үзгәреш кертү;

е) Килешүне закон таләпләренә туры китерү;

ж) алга киткән үсеш территориясе резиденты – юридик зат исеменә, юридик адресына үзгәреш кертү;

з) техник характердагы төзәтмәләр кертү.

$35^{2}$. Килешүгә бу Тәртипнең $35^{1}$ нче пунктындагы «а» – «д» пунктчалары белән күздә тотылган үзгәрешләр кертү бу Тәртипнең 2 – 19 нчы һәм 26 – 35 нче пунктларында гамәлгә ашырыла.

$35^{3}$. Килешүгә бу Тәртипнең $35^{1}$ нче пунктындагы «е» – «з» пунктчалары белән күздә тотылган үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә:

әлеге карар белән расланган Алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешү формасында:

3.3 нче пунктның 3.3 нче пунктчасында «икенче» сүзен төшереп калдырырга;

3.5 нче пунктта:

3.5.2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Килешүгә теркәлгән 1 нче кушымтада каралган инвестицион проектның төп күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә.

Шул ук вакытта һәр күрсәткеч буенча мәгънәләргә ирешмәү рөхсәт ителә:

Килешүне тормышка ашыруның беренче елында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен оештыру турында» 20 __ ел, __________, ____ нче карары белән билгеләнгән минималь зурлыкларны үтәү шарты белән;

Килешү төзелгәннән вакыттан ике еллык чор йомгаклары буенча һәм алга таба ел саен – инвестицион проектны тормышка ашыруның беренче елында һәм тулаем инвестицион проект буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен оештыру турында» 20 __ ел, __________, ____ нче карары белән билгеләнгән минималь зурлыкларны үтәү шарты белән әлеге күрсәткечләр мәгънәләреннән 25 процентка кадәр.»;

3.5.3.1 нче пунктчада «инвестицион проектның гомуми кыйммәтеннән» сүзләрен «капиталь салуларның гомуми күләменнән» сүзләренә алыштырырга;

3.5.3.2 нче пунктчада «инвестицион проектның гомуми кыйммәтеннән» сүзләрен «капиталь салуларның гомуми күләменнән» сүзләренә алыштырырга;

3.5.7 нче пунктчада «икенче» сүзен төшереп калдырырга;

4 бүлектә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Килешүнең гамәлдә булуын туктату һәм Килешүгә үзгәрешләр кертү шартлары»;

4.1 нче пунктның 4.1.1 нче пунктчада:

«д» пунктчасында «25 процентка артыграк» сүзләрен төшереп калдырырга;

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) ел йомгаклары буенча, Килешүнең 3.5.2 нче пунктчасы белән билгеләнгән рөхсәт ителгән тайпылышларны исәпкә алып, Килешүгә теркәлгән 1 нче кушымтасында күрсәтелгән төп күрсәткечнең берсенә генә булса да ирешмәү;»;

түбәндәге эчтәлекле 4.5 нче пункт өстәргә:

«4.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе белән күздә тотылган үзгәрешләрне Килешүгә кертү яклар тарафыннан өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Өстәмә килешү бу Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм аңа кул куйган көннән үз көченә керә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссияләрен төзү турында» 2018 ел, 21 апрель, 271 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 2 октябрь, 892 нче; 2019 ел, 13 июль, 573 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә оештырыла торган Алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясе хакындагы нигезләмәгә, 4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Комиссиянең төп бурычлары – Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә оештырыла торган Алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә (аңа үзгәреш кертүгә) һәм Килешү төзү (аңа үзгәреш кертү) мөмкинлеге турында яки Килешү төзүдән (аңа үзгәреш кертүдән) баш тарту турында карарлар кабул итүгә гаризаларны карап тикшерү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү тәртибенә 1 нче кушымта

«______________________________________________________»
алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясенең исеме

алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә (үзгәреш кертүгә)
гариза

____________________________________________________________ нигезендә эш итүче
_____________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис.[1])
________________________________________ муниципаль берәмлеге территориясендә
(муниципаль берәмлекнең исеме)
генә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырган
______________________________________________________________________________
(юридик зат исеме)
«_________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә (үзгәреш кертүгә) гариза җибәрә һәм «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен оештыру үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен оештыру турында» _______ ел, _________, ______ карары таләпләренә туры килә торган инвестиция проектын тормышка ашыру ниятен раслый.

Гаризага таләп ителә торган материаллар теркәлә. Мәгълүматларның дөреслеген гарантиялим.

Кушымта:

Җитәкче: _________________ ____________________ /___________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.[1]) (датасы)

М.У.[2]

____________________________________________

-------------------------------
[1] Атасының исеме – булганда.
[2] Булганда